**Класс:** 7
**Укытучы:** Гыйләҗева Эльвира Зөфәр кызы
**Программа:** БИНОМ
**Тема:** Кереш
**Максаты**: Укучыларга информатика белән бәйле әйләнә – тирә дөньябызда чолгап алган кайбер төшенчәләр белән таныштыру. Куркынычсызлык техникасын искә төшерү.

**Дәрес барашы:**

**-Хәерле көн, укучылар! Безнең уку предметыбыз “Информатика” дип атала. Аны өйрәнеп, сез информатиканың фәнни нигезләре белән танышырсыз.**

**Шулай итеп, кадерле укучылар, сез информатика дип аталган яңа белем океаны буенча йөзә башлыйсыз.**

***<u>Слайд 1</u>***

Безне чолгап алган әйләнә – тирә биниһая күптөрле.

***<u>Слайд 2</u>***

Беренчедән, бу – матди объектлар төрлелеге: утырган урындыкларыбыз, кигән киемнәребез, азык, хезмәт кораллары, транспорт чаралары, үсемлекләр, кешеләр һ. б. Матди объектлар төрлелеген билгеләү өчен, фәндә матдә термины файдаланыла.

***<u>Слайд 3</u>***

Икенчедән, бу – энергия. Хәзерге заман кешеләренең күбесе өчен энергия төшенчәсе барыннан да элек электр энергиясе белән бәйләнгән. Ләкин, электр энергиясеннән тыш, табигатьтә энергиянең башка төрләләре дә бар. Мәсәлән, җылылык энергиясе, хәрәкәттәге җисемнең механик энергиясе һәм, ниһаять, атом энергиясе.

***<u>Слайд 4</u>***

Әйләнә – тирә дөньяның өченче чынбарлыгы булып информация тора. Информация – без китаплардан, газета, радио, телевидениедән, аралаша торган кешеләрдән алган мәгълүмат, белемнәр.

**Элек – электән яшәп килә торган физика, химия, биология һәм башка фәннәр материаль дөньяны, андагы реаль объектларны һәм энергетик процессларны өйрәнә. XX гасыр урталарында яңа фән – информатика барлыкка килә.**

***<u>Слайд 5 (с закадровым голосом)</u>***

**Информатика – төрле табигатьле системаларда информацион процессларның закончалыклары, информацион процессларның автоматлаштыруның методлары, чаралары, технологияләре турындагы фән.**

***<u>Слайд 6</u>***

**-Әйдәгез әле информатика чыганагын санап үтик. Алар:** Кибернетика, информатика теориясе, алгоритмнар теориясе, ЭХМ архитектурасы

***<u>Слайд 7</u>***

ЭХМ (электрон – хисаплау машинасы) – ул компьютерлар. Информатика үсешенә этәргеч ясаучы XX гасырның иң мөхим казанышларының берсе - ЭХМ барлыкка килүе этәргеч ясады.

Бүген компьютердан файдаланучы кешеләрнең күпчелеге программаламый.Аларны кулланучылар дип атыйлар. Кулланучылар компьютерларда әзер программа белән эшлиләр, ул программалар профессиональ программистлар тарафыннан төзелгән.

XX гасыр ахыры – XXI гасыр башларында компьютер телекоммуникацияләре – глобаль компьютер челтәрләре зур үсеш алды. Сез барыгыз да, әлбәттә, Интернет турында беләсез. Бу – дөньякүләм телекоммуникация системасы. Соңгы вакытта информацияне саклау, эшкәртү һәм тапшыруның компьютер методларын белдерү өчен, информацион – телекоммуникацион технологияләр – ИКТ терминын куллана башладылар.

Ә хәзер ПК белән эшләүнең санитар нормалары һәм куркынычсызлык техникасы белән танышыйк. Компьютер белән эшләгәндә, куркынычсызлык техникасы кагыйдәләрен һәм санитар нормаларны үтәргә кирәк.

Беренчедән, компьютерның тормыш өчен куркыныч көчәнешкә ия булуын истә тотарга кирәк.

***<u>Слайд 8(с закадровым голосом)</u>***

1. Ачык торган тоташу урыннарын кагылмаска, үткәргечләрне тартмаска, систем блок корпусы ачык булганда эшләмәскә кирәк.

2.Компьютер җайланмаларына су тидерергә ярамый.

3.Компьютер төймәләренә каты басмаска

4.Сагыз чәйнәмәскә

5.Беренче аяк киеме белән кермәскә

6.Кабинетта ашамаска

7.Әшәке куллар белән компьютерга кагылмаска

***<u>Слайд 9(с закадровым голосом)</u>***

1.Компьютер каршында, арымас өчен, арканы урындык артына терәп, төз утырырга кирәк

2.Күздән экранга кадәр ара кул сузымыннан ким булырга тиеш түгел. Экранның өске кыры чама белән күз биеклегендә булырга тиеш. Карау юнәлеше экранга перпендикуляр булуы шарт, шуңа экранны азрак өскә таба борып куялар

3.30-40 минут өзлексез эшләгәннән соң, азрак туктап тору мәҗбүри. Бу вакытта бүлмәне җилләтергә кирәк

***<u>Слайд 10</u>*** ***<u>(с закадровым голосом)</u>*** (1 нче бирем) – **Укучылар дөрес җавапны сайлап алыгыз.** 1 нче бирем. Бирелгән объектларның кайсысы *матди* объектларга керә: үсемлекләр , инша , эш кораллары, хайваннар, телефон шалтыравы. **Уйлап карагыз әле!**

**<u>Вакыт 5 секунд</u>**

**Җавапларны тикшерик! Димәк үсемлекләр , эш кораллары, хайваннар *матди* объект була икән. Яхшы.**

***<u>Слайд 11 (с закадровым голосом)</u>*** (2 нче бирем) – 2 нче бирем. Бирелгән объектларның кайсысы ***энергия*** була: үсемлекләр , инша , атомлы шартлау , телефон шалтыравы, кәгазь кисәкләре януы.

**<u>Вакыт 5 секунд</u>**

**Дөрес җавап атомлы шартлау , кәгазь кисәкләре януы. Бик әйбәт.**

***<u>Слайд 12 (с закадровым голосом)</u>*** (3 нче бирем) – Бирелгән объектларның кайсысы **информация** була:

хайваннар, атомлы шартлау, хәбәрләр, үсемлекләр , белемнәр

**Вакыт 5 секунд**

**Дөрес җавап хәбәрләр, белемнәр.**

***Слайд 13  (с закадровым голосом)*** (4 нче бирем) - Информатика чыганагы нинди өлешләргә бүленә:

алгоритмнар теориясе, кибернетика, хәбәрләр, информатика теориясе ,ЭХМ архитектурасы

**Дөрес җавап алгоритмнар теориясе, кибернетика,  информатика теориясе ,ЭХМ архитектурасы**

**Шуның белән укучылар дәрес тәмам саубулыгыз, киләсе очрашуларга кадәр.**